МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ ____173/о______

П Р И К А З К                                                                                Б О Е Р Ы

«__29___»_____10_________20_21_

**2022 елга «Чиста республика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте операторының инвестиция программасын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм эшчәнлек башкару программаларын эшләү, раслау һәм төзәтү тәртибен, шул исәптән каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең план һәм факттагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм эшәнлек башкару программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә **боерык бирәм**:

1. «2022 елга «Чиста республика» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте операторының кушымтада бирелә торган инвестиция программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Программа үтәлешен контрольдә тотуны коммуналь хуҗалык идарәсенең коммуналь хуҗалыктагы инвестиция программалары бүлегенә (Р.Р.Мөхәммәтҗанова), калдыклар белән эш итү бүлегенә (Д.В.Краснова) аларның компетенциясенә ярашлы рәвештә йөкләргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.М.Фроловны җаваплы итеп билгеләргә.

**Министр** **М.М.Айзатуллин**